РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**30.01.2026** Кукмара ш. **№ 79**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2026 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 2026 елның 23 гыйнварындагы 30 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирлекләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында» 2024 елның 02 августындагы 261 номерлы Кукмара муниципаль районы Советы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 2026 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 9678,63 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2025 елның 30 гыйнварындагы 82 номерлы карарын 2026 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.М. Әхмәтшинага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2026 елның 30 гыйнварындагы 79 номерлы карарына 1 нче кушымта

2026 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында җирләү буенча исемлектәге гарантияләнгән хезмәтләрнең бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4133,15 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетен) зиратка илтү | 1330,12 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4215,36 |
| Барлыгы | 9678,63 |

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2026 елның 30 гыйнварындагы 79 номерлы карарына 2 нче кушымта

2026 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында җирләү буенча исемлеккә гарантияләнгән хезмәтләрнең бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү (киендерү) | 174,01 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3959,14 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетен) зиратка илтү | 1330,12 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4215,36 |
| Барлыгы | 9678,63 |